**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
15.01.2025

КАРАР
№ 30

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "Нурлат шәһәре һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында" 2024 елның 29 маендагы 568 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында, "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 29 маендагы 568 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы бюджетына түләүләр буенча түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 1.5нче пунктның 3нче пунктчасында "хисаптан өземтә" сүзләрен "белешмә" сүзенә алмаштырырга;

– 1.5 пунктның 4 пунктчасында "Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160_1 статьясы нигезендә бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Регламентында каралган" сүзләрен өстәргә;

– 5 пунктчаның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"амнистия турында акт яисә штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау акты яисә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты;";

– 1.5нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктчаны өстәргә:

“гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ.”.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин